ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.11.2024 г. Заинск № 612

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 12 ноябрендәге 672 номерлы, 2022 елның 10 гыйнварындагы 7 номерлы, 2018 елның 26 июнендәге 1034 номерлы, 2015 елның 20 апрелендәге 931 номерлы, 2018 елның 4 сентябрендәге 1435 номерлы, 2008 елның 31 декабрендәге 1979 номерлы карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1.1 Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 12 ноябрендәге 672 номерлы «Ташламалы транспорт картасы һәм балалар ташламалы транспорт картасы буенча гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә Зәй муниципаль районы бюджетыннан транспорт оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» карары.

1.2 Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 гыйнварындагы 7 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 12 ноябрендәге 672 номерлы «Ташламалы транспорт картасы һәм балалар ташламалы транспорт картасы буенча гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә Зәй муниципаль районы бюджетыннан транспорт оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары.

1.3 Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 25 июнендәге 1034 номерлы “Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясалганда җирле бюджет акчалары исәбеннән кире кайтарыла торган һәм (яисә) кире кайтарылмый торган нигездә өстәмә ярдәм күрсәтү очраклары тәртибен һәм исемлеген раслау турында" карары.

1.4 Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 апрелендәге 931 номерлы «Торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары.

1.5 Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 4 сентябрендәге 1435 номерлы «Күпфатирлы йортта гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру турында» карары.

1.6 Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2008 елның 31 декабрендәге 1979 номерлы “Тулай торакларны социаль файдаланудагы торак фондына күчерү турында" нигезләмәне раслау хакында” карары.

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар аны бастырып чыгару мизгеленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**